**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел:  8 (84378) 2-51-51
Факс:  8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ  МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел:  8 (84378) 2-51-51
Факс:  8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2025 елның 17 марты** **20-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 августындагы 51-РС номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 ноябрендәге 444-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 августындагы 51-РС номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 1) 7.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 7.2.1 өлеш өстәргә:

– «7.2.1 Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән объектка карата килешү төзү, килешү төзелгән вакытка мондый объект Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объекты (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) яисә ачыкланган мәдәни мирас объекты булган очракта, рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**